КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 24 ноябрь г.Казань № 1057

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы карары белән расланган «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 25 октябрь, 959 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 ноябрь, 1005 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фонды» гавами-хокукый компаниясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктта:

беренче абзацта «килешү төзергә планлаштырыла торган» сүзләрен «килешү төзелгән» сүзләренә алыштырырга;

өченче абзацта «аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, Фонд эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган булырга тиеш» сүзләрен «банкротлык процедурасында» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктның өченче абзацында «, Фонд эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмавы» сүзләрен төшереп калдырырга;

10 нчы пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фонд тарафыннан бу Тәртипнең 5 нче пунктында билгеләнгән документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);»;

дүртенче абзацта «банкротлык процедурасы билгеләнгән, Фонд эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылган» сүзләрен «банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедура билгеләнгән» сүзләренә алыштырырга;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин